**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Болгар ислам академиясен төзү һәм Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын торгызу турында

Традицион рухи кыйммәтләрне саклап калу һәм үстерү, конфессияара һәм милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту максатларында **карар бирәм:**

1. Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән мөселман дини оешмаларының Татарстан Республикасы Спас районы Болгар шәһәрендә «Болгар ислам академиясе» фәнни-мәгариф һәм дини-мәгърифәти мөселман үзәген (алга таба – Болгар ислам академиясе) төзү инициативасын хупларга.

2. Рус православие чиркәвенең Татарстан митрополиясе (Мәскәү Патриархаты) һәм Казан шәһәре Мэриясенең Казан Богородица монастыре комплексы эчендә Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын торгызу турындагы инициативасын хупларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

а) 2015 елның 31 декабренә кадәр Болгар ислам академиясен төзү һәм Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын торгызу буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шул исәптән түбәндәге урыннарда һәм көннәрдә истәлек ташлары кую буенча чаралар оештыруны күздә тотарга:

Болгар ислам академиясен төзү урынында – 2016 елның 21 маенда, Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көнендә;

торгызылачак Казан Мәрьям Ана иконасы Соборы урынында – 2016 елның 21 июлендә, Казан Мәрьям Ана иконасы табылган көндә;

б) әлеге проектларны гамәлгә ашыру өчен ирекле иганәләр җыюны, юридик һәм физик затлар, иҗтимагый һәм дини оешмаларның акча күчерүләрен оештыруга булышлык күрсәтү буенча чаралар комплексын эшләргә;

в) Болгар ислам академиясен төзүгә һәм Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын торгызуга өлеш керткән юридик һәм физик затлар истәлеген мәңгеләштерү максатларында истәлек китапларын гамәлгә кертүне һәм мемориаль билгеләр куюны күздә тотарга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2015 ел, 04 ноябрь
№ ПУ-1066